| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>**БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br><br>422640, с. Большая Елга,<br>ул.Октябрьская, дом 25 | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**<br><br>422640, Олы Елга,<br>Октябрь урамы, 25 нче йорт**,** |
|---|---|

Тел.: (84361) 25265, факс: (84361) 25265 , e-mail:Belg.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.01.2022 Олы Елга авылы №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1нче кушымта нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл(шәһәр) җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Елга авылы , Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 нчы йорт; Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.Ә.Садриев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Олы Елга  авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2022 елның  31
гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта  №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегендә**
**2022 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2646,95 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, бүтән туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан мәет куюны гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган башка зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә (бушлай) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 500,00 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2146,95 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |